Республика Татарстан

Исполнительный комитет
Менделеевского
муниципального района

Татарстан Республикасы

Менделеев муниципаль
районы
башкарма комитеты

ПОСТАНОВЛЕНИЕ

КАРАР

28.04.2022 ел

Менделеевск ш.

№308

Менделеевск муниципаль районында
ягып җылыту сезонын тәмамлау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 6 маендагы 354 номерлы карары белән расланган гражданнарга коммуналь хезмәтләр күрсәтү кагыйдәләренең 5 нче пункты, Россия Федерациясе Энергетика министрлыгының 2003 елның 24 мартындагы 115 номерлы боерыгы белән расланган җылылык энергия җайланмаларын техник эксплуатацияләү кагыйдәләренең 11.7 п. нигезендә һәм тышкы һаваның уртача тәүлеклек температурасы +8 градус Цельсий буенча һәм аннан да югарырак булганда, Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. «Газпром теплоэнерго Казань» ҖЧҖенә, районның авыл җирлекләре башлыкларына 2022 елның 11 маеннан торак йортларга җылылык бирүне туктатуны тәкъдим итәргә.

1.1 Менделеевск муниципаль районының социаль-көнкүреш билгеләнешендәге объектларына җылылык бирүне туктатып торырга:

- 2022 елның 6 маеннан спорт объектларына;
- 2022 елның 6 маеннан Менделеевск муниципаль районы Советы һәм Башкарма комитетының административ биналарына:
- 2022 елның 11 маеннан «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының Мәдәният идарәсе» МКУ объектларына;
- 2022 елның 11 маеннан «Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф идарәсе» МКУ объектларына.

2. Җылылык белән тәэмин итүче һәм хезмәт күрсәтүче оешмаларга түбәндәгеләрне тәкъдим итәргә:

2.1. 2022-2023 елларга җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларын әзерләү планнарын эшләргә һәм аларны расларга һәм күчермәләрен Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына 2022 елның 15 маена кадәр тәкъдим итәргә.

2.2. 2022-2023 еллардагы җылыту чорына җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларын әзерләүне 2022 елның 23 маеннан башларга.

2.3. Атна саен 2022 елның 23 маеннан башлап һәр сишәмбе көнне җылылык белән тәэмин итү һәм җылылык куллану объектларында әзерлек эшләре барышы турында Менделеевск муниципаль районы башкарма комитетына оператив хисап бирергә.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп тору Менделеевск муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгына йөкләргә.

Җитәкче Р.И. Беляев

КИЛЕШТЕРЕЛГӘН:

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитеты
җитәкчесенең беренче урынбасары М.А.Санков

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
төзелеш һәм ТКХ бүлеге башлыгы Р.Р. Галиева

Менделеевск муниципаль районы
Башкарма комитетының
хокук бүлеге башлыгы Е.С. Царева